**Шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә**

2022елның18 июле Кече Кабан авылы

Халык тыңлаулары «Долина Махаон» торак комплексы территориясен планлаштыру проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында» 2022 елның 20 июнендәге 6 номерлы Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы карары белән билгеләнде.

Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы нигезендә карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән): 2022 елның 22 июнендәге 43 (10180 номерлы "Кама ягы"(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Олы Кабан авыл җирлеге " бүлегендә.

Үткәрү датасы һәм вакыты: 13.07.22 елның 13 июле, 16.00 сәгатьтә.

Үткәрү урыны: 422623, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Кече Кабан авылы, Көньяк ур., 1 йорт адресы буенча урнашкан Башкарма комитет бинасы.

Катнашучылар саны: 16 кеше.

Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә:

Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Кече Кабан авылы адресы буенча урнашкан кадастр номерлары16:24:160304:293, 16:24:160304:294, 16:24:160304:529, 16:24:160304:530, 16:24:160304:531, 16:24:160304:532, 16:24:160304:512, 16:24:000000:6603булган җир кишәрлекләрендә «Долина Махаон» торак комплексы территориясен планлаштыру проекты мәсьәләсен карау.

Ачык тыңлауларны үткәрү инициаторы-««СтройУслуги-4» махсуслаштырылган Төзүче ҖЧҖ директоры Гыйниатуллин Айдар Нәҗип улы.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә 2022 елның 13 июлендәге ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Кече Кабан авылы адресы буенча урнашкан кадастр номерлары16:24:160304:293, 16:24:160304:294, 16:24:160304:529, 16:24:160304:530, 16:24:160304:531, 16:24:160304:532, 16:24:160304:512, 16:24:000000:6603булган җир кишәрлекләрендә «Долина Махаон» торак комплексы территориясен планлаштыру проекты буенча ачык тыңлаулар, үткәрү процедурасын үтәп, үткән дип санарга.

2. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Кече Кабан авылы адресы буенча урнашкан кадастр номерлары16:24:160304:293, 16:24:160304:294, 16:24:160304:529, 16:24:160304:530, 16:24:160304:531, 16:24:160304:532, 16:24:160304:512, 16:24:000000:6603булган җир кишәрлекләрендә «Долина Махаон» торак комплексы территориясен планлаштыру проекты буенча ачык тыңлауларда катнашучылардан искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керде:

Кудрявцева М.Г.: кадастр номерлары 16:24:160304:293, 16:24:160304:294, 16:24:160304:529, 16:24:160304:530, 16:24:160304:531, 16:24:160304:532, 16:24:160304:512, 16:24:000000:6603 булган җир кишәрлекләрендә шәхси торак төзелеше йортларын рөхсәт ителгән кулланугa ия, бернинди күпкатлы төзелеш турында сүз дә юк, документларда ул юк. Моны яңадан карарга кирәк.

Кудрявцева М.Г.: ни өчен керү һәм чыгу юллары Кече Кабан т.п. аша башкарыла? Хәтта хәзер дә без тыныч кына чыга алмыйбыз. Ә үз комплексыгызны төзегәннән соң, бездә икенче Көек булачак түгелме соң?

Кудрявцева М.Г.: сезнең тәкъдим ителгән вариант буенча бөтен автомобильләр Шоссейная урамындагы тар тамакка агылачак. Ә моңа юл куярга ярамый, бу күп сәгатьлек бөкеләргә китерәчәк.

Шархемуллин Б.Ф.: сез әйтәсез ИЖС белән янәшә 3 - 5 катлы йортлар, ә ИЖС белән комплекс арасындагы юл кайда уза?

Абдуллина Э.М.: балалар бакчасы һәм мәктәп, йортлар янында парковка җитәрлек дәрәҗәдә каралмаган. Балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә бөкеләр булачак. 20 мең кешегә 10 меңнән дә ким булмаган автомобиль туры килә. Халыкка автотранспортын кая куярга? Авыл юлларында машина кую урыннары җитмәсә, үз машиналарын юлда ташлап калдырачаклар.

Абдуллина Э.М.: безнең җирлек балаларына балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә керү мөмкинлеге булачакмы соң?

Косарева Т.И.: ничек инде 20 мең кешегә 260 урынлы ике балалар бакчасы гына карарга мөмкин? Балалар бакчаларында урыннар ихтыяҗы чынбарлыкны канәгатьләндермәячәк.

Борисова Е.С.: канализация сулары кая агачак?

Борисова Е.С.: су белән тәэмин ителү ничек булачак?

Абдуллина Э.М.: Олы Кабан авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлауларда «Долина Махаон» вәкиле ИЖС ның катлы булуы 3 катлы йорттан үсә бару юлы белән төзеләчәк , дип сөйләде. Ә бу проектта без ИЖС янында 3 каттан артык икәнен күрәбез. Ни өчен концепциясе үзгәрде?

Шәрхимуллин Б.Ф.: ИЖС янында парк, җәяү йөрү зонасын калдырырга тәкъдим итәбез.

Зарипова Р.Г.: авыл җирлегендә 12 катлы йорт төзергә планлаштырасыз, йортларның катларын киметүегезне сорыйбыз.

Кудрявцева М.Г.: Кече Кабан авылында яшәүчеләрне борчыган төп мәсьәлә- безнең авылга керү һәм чыгу юлы. Сезне «Долина Махаон» га керү һәм чыгу өчен Казан – Оренбург автоюлында чишелеш төзү мөмкинлеген каравыгызны сорыйбыз. Без мондый планлаштыру проектына каршы. Барлык теләкләребезне исәпкә алып, яңа проект тәкъдим итүегезне сорыйбыз.

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының башкарма комитетына әлеге проектны, кергән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр белән бәйле рәвештә, яңадан карарга тәкъдим итәргә.

4. «СтройУслуги-4» ҖЧҖ вәкилләренә, барлык искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, яңа проект эшләргә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге бәяләмәне“Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Олы Кабан авыл җирлеге" бүлегендә. бастырып чыгарырга.

Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы Р.Ш. Илһамов